«Без – зур бер гаилә»

Марат Әхмәтов:

«Башка илләрдә фермерлык тармагы гасырлар буена формалашкан. Ә безгә бу эшләрне берничә ел эчендә башкарып чыгарга кирәк. Авыр, әлбәттә. Әмма шуны әйтәсе килә: без – зур бер гаилә. Мин сезнең һәрберегезне, күрсәткечләрнең һәм нәтиҗәләрнең нинди булуына карамастан, бик югары бәялим».

3 БИТ

Иң яхшысы – шәхси үрнәк

Адел Вафин:

«Сәламәтлегебез – үзебезнең кулларда, шуңа да кеше даими тикшеренеп торырга тиеш».

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 7.02.2017 | №12 (5774)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«БОЗ» КУЗГАЛДЫ

Үз куышың булу – зур бәхет. Социаль ипотека программасына бер кочак документлар җыеп тапшырганда да әнә шундый татлы хыяллар белән яна кеше. Әмма күпләребезгә, үз куышы булганчы, шактый катлаулы юллар аша узарга һәм берничә еллар көтәргә туры килә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Шулай да берничә ел дәвамында фатирларын көтә-көтә көтек булып хәлдән тайган халыкның, ниһаять, акрынлап кына булса да, быел өй туйлары уздырырга өметләре уяна башлады. Шушы көннәрдә социаль ипотека программасы кысаларында, 306 фатирлы чираттагы йорт төзелеп бетте. Әлеге йорт Казанның Идел буе районының Оренбург тракты урамында урнашкан. Бу хакта Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы хәбәр итте.

Хәзерге вакытта йөзгә якын гаилә фатир ачкычларын алган да инде. Фатирлы булу бәхетенә ирешкәннәр өчен бу зур бәйрәм, билгеле. Социаль ипотека программасында чиратта торучылар белән беррәттән, мондый бәхет Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларның тол хатыннарына да тәтеде.

Исегезгә төшерәбез, ел башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, бүгенге көндә республикада социаль ипотека программасы нигезендә төзелеп килә торган иң эре һәм халыкта күп сораулар тудырган «Салават күпере» торак комплексына барып, андагы эшләрнең барышы белән танышкан иде. Ул вакытта Президент, 10-13нче кварталларны карап, йортларны куллануга тапшыруны тизләтергә кирәк, дип белдерде. Шуннан соң берничә көн узуга ук, «Ак Таш» компаниясе 102 фатирлы 13-4 йортын файдалануга тапшыруга рөхсәт тә алды.

Шушында ук Президент объектларда эшләүче кешеләрнең аз булуына карата да тәнкыйть сүзләре әйткән иде. Тәнкыйть кәнфит түгел, шуны истә тотып булса кирәк, 10 гыйнвардан соң «Салават күпере» торак комплексы объектларында эшләүче белгечләрнең саны дүрт тапкырга артты. Хәзерге вакытта биредәге йортларны төзүдә 2000 кеше эшли.

Шөкер, шушы көннәрдә дәүләт төзелеш күзәтчелеге «Ак Таш» төзелеш компаниясенең 255 фатирлы тагын 13-1 санлы йортын кабул итәргә тиешлеге дә киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булды. Шуннан соң ул файдаланышка тапшырылачак, дип хәбәр итә җитәкчеләр. «Салават күпере» торак комплексының чираттагы йортлардагы фатир ачкычларын исә мартта бирергә тиешләр.

Гомумән алганда, Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Ирек Фәйзуллин китергән мәгълүматлар буенча быел, социаль ипотека программасы нигезендә, 534,1 мең квадрат метр торакны кулланылышка тапшыру планлаштырыла. Бу, 2016 ел белән чагыштырганда, 45 процентка күбрәк дигән сүз. Узган ел Балык Бистәсе, Апас, Сарман, Ютазы, Кайбыч, Чирмешән, Чистай, Питрәч, Лаеш, Тукай, Әтнә, Югары Ослан һәм Теләче районнары торак төзелеше буенча еллык планны тулысынча үтәгән.

Инде хәзер җитәкчеләрнең максат итеп куелган планнары тормышка ашсын да, фатир ачкычларын берничә ел дәвамында зарыгып көтеп алган халык үз куышларында тынычлык белән яшәсен иде, дип телисе генә кала.

Иннополис – алгарыш шәһәре

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Хөкүмәт йортында кичә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Иннополис шәһәре үсешенә кагылышлы киңәшмә үткәрде.

Иннополиска яңа резидентлар табу, компанияләрне квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү – төп мәсьәләләр, дип белдерде Президент.

Республиканың мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов докладында әйтелгәнчә, Югары Ослан муниципаль районы җирлегендә урнашкан Иннополиста бүген 46 компания эшли. Шуларның 39ы узган ел ахырында резидент һәм партнер дәрәҗәсе алган. «Сбербанк-Технологии», «Касперский», «Яндекс», «БАРС групп», «UFS универсаль финанс система» – иң әһәмиятле компанияләр исемлегендә.

– Иннополиста 544 эш урыны булдырылды инде. Узган елның сентябрендә Ресурс үзәге оештырылды. Аның максаты – компания-резидентларны квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, – дип әйтеп үтте Роман Шәйхетдинов.

Иннополис мэры Руслан Шагалиев алгарыш шәһәрчеге белән таныштырды.

– Иннополиста хәзер 2,5 меңнән артык кеше яши. Бакчага һәм мәктәпкә 327 бала йөри. Шәһәрчектә, гомуми исәптә, 80 компания һәм шәхси эшкуар эшчәнлек алып бара, – диде ул.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, киңәшмәдәге сөйләшүгә йомгак ясап, Иннополиска мәгълүмати технологияләр өлкәсендә эшләүче компанияләрне җәлеп итү буенча эшне көчәйтергә, инновацион шәһәр территориясендә яңа объектлар (торак йортлар, юллар) төзелешендә һәм аларны куллланышка тапшыруда срокларны сакларга кушты.

Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстанның Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясенең XVII съездында фермерларга мөрәҗәгать итеп:

> **“БЕРСЕ АРТЫННАН БЕРСЕ ТИКШЕРҮ КИЛЕП КЕНӘ ТОРА, ДИСЕЗ. СЕЗ БИТ ҮЗЕГЕЗ ДӘ БИК КУНАКЧЫЛ: ТАВЫГЫН, ЙОМЫРКАСЫН, СӨТЕН-КАЙМАГЫН ТОТТЫРЫП ҖИБӘРӘСЕЗ. ШУҢА КИЛӘ ДӘ ИНДЕ АЛАР.”**

Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәр

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәр кыла. Аның җитәкчелегендәге республика делегациясе корольлекнең башкаласы Эр-Рияд һәм дәүләтнең икътисади башкаласы булып саналган Җидда шәһәрендә булырга планлаштыра.

Сәфәре барышында Рөстәм Миңнеханов изге урында кече хаҗ кылырга да ниятли. Татарстан Мөселманнары диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин аны озата бару өчен шулай ук Согуд Гарәбстанына киткән, дип яза «Бизнес-онлайн». Мөфти анда быелгы хаҗны оештыру мәсьәләләре буенча да очрашулар үткәрергә җыена.

Инвестицияләр күләме арта

2016 елда чит ил компанияләре Татарстан икътисадына 422 млн доллар акча керткән. Бу саннар бүген Татарстанның Инвестицияләр үсеше агентлыгы коллегиясенең йомгаклау утырышында китерелде, дип хәбәр итә «Татар-информ». Коллегия эшендә Татарстанның Премьер-министры Илдар Халиков катнашты.

rbc.ru

Узган ел Инвестицияләр үсеше агентлыгы хезмәткәрләре эш алып барган илләрнең саны 40тан да артып киткән. Алар тырышлыгы белән, Татарстан берничә эре халыкара күргәзмәдә һәм форуда катнашты. Бергә тә Төркия, Германия, АКШ, Кытай, Франция, Чехия белән ныклы бәйләнышлар урнаша.

– Һәр ай саен Татарстанда 15 уртак предприятие ачыла. 2016 елның I кварталында Татарстан инвестицияләрне көткәннән дә күбрәк җәлеп итте. Бөтенесе дә аңлый, санкцияләр беркемгә дә файда юк. Әмма безне барган бер җирдә якты йөз белән каршы алдылар. Тиздән үзебез дә җавап визиты белән килүчеләрне кабул итәчәкбез, – дип басым ясады Татарстанның Инвестицияләр үсеше агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина.

Илсур Метшин:

«Абу-Дабига кадәр «үсәргә» вакыт бар әле»

Казанда 1-3 февраль көннәрендә «WorldSkills» чемпионатының «Яшь профессионаллар» дигән III төбәк этабы үтте. Биредә «WorldSkills» таләпләре буенча 78 компетенция, «JuniorSkills» буенча (балалар арасындагы ярыш) 19 компетенция тәкъдим ителде.

Чемпионатта «WorldSkills» юнәлешендә 595 студент һәм 527 эксперт, «JuniorSkills» буенча 220 кеше һәм 120 эксперт катнашты. Бәйге нәтиҗәләре буенча, милли чемпионатның ярымфиналында һәм финалында Татарстан даны белән яклап кемнәр катнашасы ачыкланды.

Казан Башкарма комитетының Икътисади үсеш комитеты рәисе Артур Вәлиәхмәтов белдергәнчә, аларга беркетелгән «Флористика», «Ресторан хезмәте», «Пешекче һөнәре», «Кондитерлык эше» һәм «Чәчтарашханә сәнгате» буенча Казанның махсус урта һөнәри белем бирү йортларында укучы студентлар җиңгән.

Казан мэры Илсур Метшин 2019 елда һөнәри осталык буенча «Worldskills» дөнья чемпионатында Казан студентлары илнең җыелмасына керергә тиеш дигән максат куйды.

– Абу-Даби шәһәрендә 2019 елда эшче һөнәрләр буенча үтәчәк чемпионатка кадәр «үсәргә» вакыт бар әле. Компетенцияләр күп, бөтен җирдә дә көндәшлеккә сәләтле булырга кирәк. Бу эшкә җитди карыйк, – диде Илсур Метшин.

Артур Вәлиәхмәтов «WorldSkills» чемпионатын үткәрергә ярдәм иткән эшмәкәрләргә рәхмәт сүзләрен җиткерде һәм башка компанияләрне алардан үрнәк алырга өндәде. Ул чемпионат эшче һөнәрләрен популярлаштыру, сыйфатлы белгечләр туплау өчен дә әһәмиятле булуына басым ясады.

– Биредә укучылар үзләренең квалификацияләрен, белемнәрен һәм осталыкларын арттыра ала. Иганәчеләрнең «Флористика», «Ресторан хезмәте», «Пешекче һөнәре», «Кондитерлык эше» һәм «Чәчтарашханә сәнгате» компетенцияләре өчен мәйданчыкларны әзерләү эшенә тотылган ярдәменең күләме 16 млн 300 мең сум тирәсе булды, – диде ул.

Татар дәүләт «Әкият» курчак театры коллективы, Татарстанның халык артисты

Тимергали Зиннур улы ЗИННУРОВның

вакытсыз фани дөньядан китүе сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының, хезмәттәшләренең авыр кайгысын уртаклаша.

Тимергали Зиннур улы 1967-1982 елларда безнең театрда эшләгән артист буларак та безгә якын дус, тугры иптәш, олы хөрмәткә лаек, изге җанлы якты шәхес иде.

Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын!

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Марат Әхмәтов:
«Без – зур бер гаилә»

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Бүген Татарстан авылларында 912,6 мең кеше яши. Авыл кечерәя, картая. Россия күрсәткечләре буенча, ел саен авылларда 80-90 мең кеше кими, әмма бу безне акламый да, бизәми дә. Авыл үз йөзен югалта бара. Бары монда гына без үзебезнең үзенчәлекләребезне – телебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, мәдәниятебезне саклап кала алабыз. Казанга килеп югалалар: русы – татарга, чувашы керәшенгә өйләнә. Шулай буталып бетәбез дә ана телен онытабыз. Ә бит җәмгыять гореф-гадәтләрдә тора. Эшмәкәрлеккә ярдәм итүнең зур миссиясе әнә шуннан гыйбарәт.

Татарстанның Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясенең XVII съездында чыгыш ясаганда Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әнә шулай дип белдерде.

2016 елның ил өчен авыр булуы беркемгә дә яңалык түгел. Әмма шушындый шартларда да республикада планлаштырылган эшләрнең күбесе башкарылган. Узган ел авыл хуҗалыгы өлкәсендә 238 млрд сумлык товар җитештерелгән. Татарстан бу тармак буенча Россиядә дүртенче урында тора. Бүгенге көндә республикада 5000гә якын фермер, 450 мең шәхси ярдәмчел хуҗалык, йөзләгән авыл хуҗалыгы оешмалары һәм кооперативлары бар.

– Сез бирердә авылның иң актив, алга киткән, креатив кешеләрен тәкъдим итәсез. Татарстанның эчке тулаем продуктының яртысыннан артыгын сез җитештерәсез. Бу саннар артында көндәлек хезмәт тора, – дип рәхмәт сүзләрен җиткерде Фәрит Мөхәммәтшин съездда катнашучыларга.

Аның әйтүенчә, бүген республикада 35 программа тормышка ашырыла. «Эш башлап җибәрүче фермерларга ярдәм» һәм «Гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» программалары кысаларында, соңгы биш елда 11 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Шуларның 2 млрд сумы узган ел файдаланылган. 2017 елда да фермерларга ярдәм итү киметелмәячәк. Быел бюджеттан авыл хуҗалыгы өлкәсенә 800 млрд сум күләмендә акча бүлү каралган. Съезд барышында Татарстанның авыл хуҗалыгы өлкәсендә чираттагы пилот проектларына кергәнлеге дә мәгълүм булды. Аның оештыру комитеты рәисе – РФ Хөкүмәте җитәкчесенең беренче урынбасары Игорь Шувалов. Әлеге проект илнең биш төбәгендә сынап каралачак. Марат Әхмәтов һәм республиканың икътисад министры Артем Здунов эшче төркем составына кертелгән.

Шулай ук социаль әһәмияткә ия программалар нигезендә, мәдәният йортлары, ветеринар, фельдшерлык пунктлары, полицияләр өчен офис-йортлар төзелә. Бу программалар халыкны авылларда калдырырга ярдәм итәргә тиеш, дип саный җитәкчеләр. Кызганыч, яшьләр генә елдан-ел кими. Югыйсә, тырыш, булдырам, дип тотынган кешегә төрле тармак буенча эшмәкәрлек эшен җәелдерергә мөмкин. Соңгы елларда авылларда фермерлык белән генә түгел, кошчылык, умартачылык, яшелчәләр үстереп сату эшләре, һөнәрчелек тә киң җәелде.

– Һәм без боларның барысына да ярдәм итәргә тиеш. Ләкин сез дә үз чиратыгызда шушылар белән кызыксынган кешеләрне табарга ярдәм итегез, башкаларны да кызыксындырыгыз. Алар сезнең көндәшләр булыр дип курыкмагыз. Район башлыклары белән дә актив эш алып барыгыз, – дип мөрәҗәгать итте ул фермерларга.

«БЕРЛӘШЕГЕЗ!»

Съездда катнашучыларга мондый тәкъдим юктан гына ясалмады. Продукцияне җитештерү генә түгел, әле бит аны кулланучылар базарына китереп җиткерергә дә кирәк. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, бу мәсьәләдә нәкъ менә кооперативлар, агросәнәгать парклары, башкаланың һәр районында эшләп килә торган ярминкәләр ярдәм итә.

Бүгенге көндә республикада 4700 фермерлык хуҗалыгы бар. 200 гаилә фермасы исәпләнә, әмма аларның күпчелеге үз көченә генә ышана. 72 кооператив төзү планы куелса да, бүгенгә шуның 31е эшли. Моннан кала, Казанда һәм Чаллыда агросәнәгать парклары бар. Киләчәктә әлеге паркларның кечкенәләре авылларда да булдырылачак. Мәсәлән, Зәй районында шундый бина төзеләчәк.

– Җитештерү һәм хезмәт күрсәтүгә авыл җирлегендә яшәүчеләрне җәлеп итә алдык. Хәзер алар җитештергән продукцияне кулланучыларга китереп җиткерү, аны базарларда сату өчен юл картасы булдырырга кирәк. Бу бик җитди мәсьәләләрнең берсе булып кала, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Киенлыклар һәм проблемалар, әлбәттә, бик күп. Аларның кайберләре хәтта хәл итеп тә бетерә торган түгел. Әмма кыенлыклар акчада гына түгел. Чөнки хәзерге заманда бернинди бизнес та мөстәкыйль рәвештә генә алга бара алмый, дип саный Татарстан Премьер-министр урынбасары – республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов.

– Базар тулган, шуңа да продукцияләрен гамәлгә куюу системага салынмаган товар җитештерүчеләргә бик авыр. Урыннарда административ каршылыклар, эре җитештерүчеләр белән көндәшлек шулай ук кыенлыклар тудырып тора, – ди ул.

Аның фикеренчә, фермерлар азык-төлек җитештерергә өйрәнде, күбесенең бу эше бик яхшы бара.

– Кайберәүләрегезнең үсеш өчен ресурслары да барлыкка килә. Әмма бездә һаман сезнең продукцияне сату системалаштырылмаган. Өстәвенә, эшкәртүчеләр күп күләмдәге товар белән кызыксына. Мәсәлән, бер литр сөтне генә алыйк. Сез аны 200-300 литр тапшырасыз икән, прицеплы «КАМАЗ»лап тапшыручыга караганда, бәясе ике сумга азрак була. Шуңа да без сезне кооперативларга берләштерергә тиеш. Сезнең арада мөнәсәбәтләр мөмкин кадәр ачык, ышанычлы булырга тиеш, – дип мөрәҗәгать итте министр.

Әмма нинди генә проблемалар белән килсәләр дә, министрның ишеге һәрчак ачык булачагын белеп таралышты бу көнне фермерлар.

– Башка илләрдә фермерлык тармагы гасырлар буена формалашкан. Ә безгә бу эшләрне берничә ел эчендә башкарып чыгарга кирәк. Авыр, әлбәттә. Әмма шуны әйтәсе килә: без – зур бер гаилә. Мин сезнең һәрберегезне, күрсәткечләрнең һәм нәтиҗәләрнең нинди булуына карамастан, бик югары бәялим. Һәрберегез өчен ачыкмын – сезнең проблемаларыгыздан курыкмыйм. Мин аларны тыңларга, ишетергә әзер. Проблемаларны хәл итәр өчен сез миңа иртән дә, кич белән дә мөрәҗәгать итә аласыз, – диде Марат Әхмәтов.

ҖИЛӘК-ҖИМЕШ БАКЧАЛАРЫ КИРӘК

Республикада җитештерелгән яшелчәләрнең – 14,4, итнең – 3,4, сөтнең – 8,2 проценты, ә бөртекнең биштән бер өлеше крестьян-фермер һәм шәхси ярдәмчел хуҗалыкларда җитештерелгән. Ә менә җиләк-җимеш үстерү буенча Татарстан калыша әле. Республикага 70 млрд сумлык җиләк-җимеш читтән кертелә. Алар арасында үзебездә үстерә алырлык алма, чия кебекләре дә бар. Шуңа күрә дә әлеге мәсьәләгә карата Фәрит Мөхәммәтшин үз фикерен җиткерде.

– Бер елны кыш салкын булганнан соң, без җиләк-җимеш бакчалары үстерүне ташладык. Безнең климат шартларында да Татарстан җиләк-җимеш үстерү белән гомер буе җитди шөгыльләнде. Алма, чия үсә торган зур мәйданнар бар иде. Дөрес, Әлмәт һәм тагын берничә районда җиләк кырлары белән шөгыльләнүчеләр дә бар. Әмма бу эш киләчәктә системалы башкарылырга һәм без моңа ярдәм итәргә тиеш, – дип саный ул.

Паркларга пәрәмәч ашарга барырбыз

Казан мэры Илсур Метшин бер әңгәмәсендә: «Бала чакта Горький паркында ашаган пәрәмәчнең тәме бүгенгедәй хәтердә», – дигән иде.

Шушындый мөмкинлек тагын барлыкка килә. Башкалада киләсе җәйдә утыз паркка һәм скверга 127 вакытлы сәүдә ноктасы урнаштырыла. Аларда тәмле-тәмле ризыклар, туңдырмалар, сувенирлар тәкъдим ителәчәк, фото хезмәте күрсәтеләчәк.

– Ләкин паркларлардагы һәм скверлардагы сезонлы сәүдә ноктадарында сыра сатылмаячак, – дип алдан ук искәртеп куйды шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Иван Кузнецов. – Спорт пропагандалана, прокат нокталары, аттракционнар эшләячәк. Тәвәккәлрәкләр һава шарында күккә күтәрелә.

Казанда барлыгы 628 җәйге сәүдә ноктасы ачу ниятләнелә. Аларның күбесе Җиңү паркы, Горький исемендәге үзәк мәдәният һәм ял паркы, «Крылья Советов» паркы, «Казан» гаилә үзәге тирәсендә урын ала.

– Иске Татар бистәсендә дә казанлылар һәм туристлар күп була. Бистәдә кибетләр бар, Кабан күле ярындагы, инде халык гадәтләнгән сәүдә рәтләре дә гөрләячәк, – диде Иван Кузнецов.

«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә мэр Илсур Метшин җәйге сәүдә урыннарына аукционнарны апрель аенда ук төгәлләп, эшкуарларга май бәйрәмнәреннән үк эшчәнлекләрен башларга шартлар тудырырга чакырды.

– Җәйге сәүдә оештырганда, башка илләрнең тәҗрибәсен кулланырга, Казанда халыкара спорт чаралары узуын да исәпкә алырга кирәк, – диде Илсур Метшин.

Казанда җәйге сәүдә урыннарына аукционнар үткәрүгә, эшне оештыруга быел шәһәрнең Кулланучылар базары комитеты җаваплы. Элек бу вәкаләт Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр комитеты карамагында иде. Җәйге сәүдәгә, аукционнарга кагылышлы хәбәрләр Казан муниципаль берәмлеге рәсми сайтының (kzn.ru) Кулланучылар базары комитеты битендә бирелеп барылачак.

Дамир БӘДРИЕВ.

Иң яхшысы – шәхси үрнәк

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының еллык коллегиясе быел Фәннәр академиясе бинасында узды. 2016 ел онкология авыруларына каршы көрәшкә багышланганга, кунакларны ишегалдында ук шешләр барлыкка килгән әчәк рәвешендәге үзенчәлекле символик эшләнмә каршы алды. Чара кысаларында медицина өлкәсендәге алдынгы проектларны чагылдырган күргәзмә дә оештырылган иде. Нәтиҗәләр ясау, киләсе елга медицина өлкәсендә үсеш стратегияләрен билгеләүгә юнәлтелгән коллегиядә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия сәламәтлек саклау министры ярдәмчесе Виталий Флек, чит ил кунаклары да катнашты. Чарада яңгыраган төп нәтиҗәләргә тулырак тукталыйк.

minzdrav.tatarstan.ru

Эльвира МОЗАФФАР

СӘЛАМӘТЛЕГЕБЕЗ – ҮЗЕБЕЗНЕҢ КУЛЛАРДА

Былтырның төп нәтиҗәсе ул –үлүчеләр саны кимү һәм уртача гомер озынлыгын арттыру, дип саный министр.

– Соңгы алты елда медицина өлкәсендә куелган тырышлыклар заманча технологияләргә нигезләнеп ярдәм күрсәтү системасын җайга салу мөмкинлеген бирде, – ди ул.

Былтыргы нәтиҗәләр буенча, Татарстанда уртача гомер озынлыгы 73 яшькә җиткән. Үлүчеләр саны, 2015 ел белән чагыштырганда, 1586 кешегә кимрәк (тулырак инфографикада.)

Былтыр, беренче тапкыр, онкология авыруларыннан үлүчеләр санын 1 процентка гына булса да киметә алдылар. Бу өлкәдә эш 2017 елда да дәвам итәчәк. Быел Әлмәттә нур терапиясе төбәк үзәге ачарга ниятлиләр. Әлегә бу проект дәүләт экспертизасы үтә. Ул «Татнефть» компаниясе ярдәме белән тормышка ашырыла. Оешма үзәк төзелешенә 300 миллион сумнан артык инвестиция кертергә җыена.

– Күп чыгымнар таләп итсә дә, республиканың көньяк-көнчыгышында яшәүчеләр өчен бу үзәк бик кирәк. Онкология белән авыручыларның 70 проценты нур терапиясенә мохтаҗ, – дип саный министр.

Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе белән, планда – Чаллыда да төбәк үзәген булдыру.

Өч бала анасы, ракны җиңгән Юлия Ивашкевич, үз мисалында, яман шеш белән ничек көрәшүе турында сөйләде. Ул шулай ук онкология авыруларыннан дәваланучыларның «Мы вместе — Без бергә» җәмгыяте эшчәнлеге белән дә таныштырды. Биредә ракны бассейн, спорт, әкиятләр ярдәмендә дә дәвалыйлар икән. (Бу хакта тулырак газетабызның киләсе саннарыннан укый аласыз.) Авырудан, химия терапияләрдән дә курыкмаска өндәде Юлия. Шулай ук «чит илдә дәвалану нәтиҗәлерәк» дигән имеш-мимешләрнең дә дөреслеккә туры килмәвен, күкрәк яман шешен Татарстанда да тиешенчә дәвалап булуына басым ясады.

– Сәламәтлегебез – үзебезнең кулларда, шуңа да кеше даими тикшеренеп торырга тиеш, – ди сәламәтлек саклау министры Адел Вафин.

Былтыр республикада 600 меңгә якын кеше диспансеризация узган. Авыруларны беренчел стадиядә ачыклау мөһим. Сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләренең авыруларны башлангыч чорда билгеләргә мөмкинлек биргән әлеге өлкәгә акчалар кертүен дә хуплады министр.

ГАИЛӘДӘ ӨЧ БАЛА ГАДӘТИ КҮРЕНЕШ БУЛЫРГА ТИЕШ

Узган елның тагын бер мөһим вакыйгасы – Республика клиник хастаханәсе каршында Перинаталь үзәк ачылу. Бала тудыру вакытында 70 процент очракта күзәтелгән төрле патологияләрне исәпкә алсаң, җитлекми туган сабыйларга югары технологияле, сыйфатлы ярдәм күрсәтә торган әлеге үзәк аеруча кирәк. Перинаталь үзәктә елына 9 мең бала туачак дип планлаштырыла. Президент Рөстәм Миңнеханов исә чыгышында бу теманы да читтә калдырмады.

– Соңгы алты елда туучылар саны артты, шулай да былтыр балаларның азрак тууы борчый. Дөрес, бу демографик хәл белән дә бәйле. (P.S.: хәзер күбесенчә 1990 елларда туучылар гаилә кора, ә алар чагыштырмача аз.) Шулай да халыкка, гаиләдә өч бала гадәти күренеш булырга тиеш, дигән фикерне җиткерсәк иде. Хатын-кызлар өченче, дүртенче балаларын да тапсыннар өчен, дөрес сүзләрне табу, стимул булдыру мөһим. Моны шәхси үрнәктә күрсәтергә кирәк, – диде Президент, елмаеп.

Аның сүзләрен хуплап, зал алкышларга күмелде.

СЫРХАУХАНӘЛӘР ЯҢАРТЫЛАЧАК

Казан шәһәренең 18нче сырхауханәсендә 67 мең кеше теркәлгән. Республикада гамәлгә ашырыла башлаган «Дустанә сырхауханә – Татарстан стандарты» проектына беренчеләрдән булып кушылган сырхауханә бу. Әлеге проектта иң мөһиме – халык өчен уңайлы мохит тудыру. Монда пыяла тәрәзәле регистратура бүлмәләре дә юк, медицина персоналы һәр клиент белән янына басып сөйләшә. Табибның пациент белән аралашу вакыты да 15 минутка кадәр озайтылган. Авыру янына өйгә барырга туры килсә, моны махсус фельдшер төркеме башкара. Алар больничный кәгазен дә рәсмиләштерә, кирәкле анализларны да ала, беренчел ярдәм дә күрсәтә.

Үткәрелгән сораштырулар буенча, халыкның 76 проценты медицина ярдәменнән канәгать. Шулай да электрон чиратка язылуларның тулы көченә файдаланылмавы, сырхауханәгә шалтыратып булмау кебек сораулар күпләрне борчый. Шул ук проблемаларны Президент та искәртте.

– «Халык контроле» порталына, интернеттан шәхсән үземә дә медицинага кагылышлы шикаятьләр килә, –диде Рөстәм Миңнеханов.

Бу өлкәдә Адел Вафинга социаль челтәрләрдәге мөрәҗәгатьләргә карата игътибарлы булырга кушты.

– Безгә сырхауханәләрне төзекләндерү мәсьәләсенә җитди карарга кирәк. Быел тагын бер кат тикшереп, мөмкинлекләребезне чамалап, кайбер сырхауханәләрне капиталь ремонт программасына кертербез. Халык кайда гына яшәсә дә, сыйфатлы медицина ярдәме алырга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Менә инде биш ел авыл җирендә медицина өлкәсен модернизацияләүгә зур игътибар бирелә. 2012 елдан бирле 368 модульле фельдшер-акушерлык пункты салынган, үзәк хастаханәләр төзекләндерелгән, кадрлар мәсьәләсе хәл ителгән. Шулай да ремонт таләп ителгән объектлар бар әле. Авылда сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү программасы быел да дәвам иттереләчәк.

Чарада шәхси клиникалар мәсьәләсе дә күтәрелде.

– Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләтнеке булмаган медицина учреждениеләрен дә күзәтүгә алырга тиеш. Анда тәртип бозулар күзәтелә икән, җитди чаралар күрелсен, – диде Президент.

Ашыгыч ярдәмне тизләтү максатыннан, Татарстанга «Ансат» вертолеты кайтарылачагы да хәбәр ителде.

– Бу алдагы ике ел чараларга аеруча бай булыр. Башкалага кунаклар, спортчылар, туристлар да күп киләчәк. Шуңа да медицина хезмәткәрләренә барысына да әзер булырга кирәк. Бүген халыкка һәр өлкәнең эшенә бәя бирү мөмкинлеге тудырылган. Бары сыйфатлы эш күрсәтеп кенә халык хөрмәтен казанып була, – диде Рөстәм Миңнеханов.



Урман эчләренә керсәң...

Бүгенге көндә республиканың 17,6 процентын урманнар били. 2010 елда бу күрсәткеч 17,4 процентка тигез булган. Дөньякүләм таләпләр буенча сәламәтлек һәм уңайлы мохит өчен бер кешегә 0,4 гектар урман туры килергә тиеш. Әгәр шулай булса, Татарстан мәйданының 25 процентын урманнар биләр иде. 2016 елда 1560 гектар мәйданда урман утыртылган. Бу саннар Урман хуҗалыгы министрлыгының еллык коллегиясендә әйтелде.

minleshoz.tatarstan.ru

Министрлыкның иң зур горурлыгы – алтынчы ел рәттән республика җирлегендә урманнарда янгыннар булганы юк. Урманны законсыз рәвештә кисү очрагы буенча 27 җинаять эше ачылган, хәтта 16 кеше хокукыннан мәхрүм ителеп, рәшәткә артына да утыртылган.

Урман хуҗалыгы министры Алмас Нәзиров чыгышыннан күренгәнчә, бүгенге көндә министрлык Төркиянең «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» агач эшкәртү компаниясе белән эшли. Узган ел «Алабуга» икътисади зонасында урнашкан Төркия заводына 436 мең кубометр агач сатылган. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 15 процентка күбрәк.

Коллегиядә министрның урман хуҗалыгы өлкәсендәге уңышларын тыңлап оеп утырган халыкны табигатьне саклау прокуратурасыннан Олег Дәминов сискәндереп җибәргәндәй булды.

Төбәкара табигатьне саклау прокуроры урынбасары Олег Дәминов белдергәнчә, Лаеш районы Вороновка авылында урман участогын законсыз биләп алу факты ачыкланган. Анда 300 төп агач киселеп, 900 мең сумлык зыян салынган. Суд карары нигезендә, әлеге участок дәүләт урман фондына кире кайтарылырга тиеш булган. Олег Дәминов әйтүенчә, Урман хуҗалыгы министрлыгы бу юнәлештә бернәрсә дә эшләмәгән. Югыйсә, әлеге очракта прокуратура урманчыларны яклап чыккан лабаса.

Алмас Нәзировның җавабыннан күренгәнчә, әлеге мәйдан урман фондына карамый, ачыкланмаган сораулар бар һәм суд әлегә соңгы ноктаны куймаган.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯ

Чүп-чардан арыначакбыз

Татарстанда һәм Мәскәү өлкәсендә калдыкларны утильләштерүнең яңа технологиясен куллана башлаячаклар, дип хәбәр итә «Татар-информ».

2017 елда Россиядә «Калдыкларны нольдә күмү» пилот проекты старт ала. Бередә 2017-2020 елларда коммуналь каты калдыкларны термик зарарсызландыру буенча Мәскәү өлкәсендә дүрт һәм Казанда бер завод төзелеше күздә тотыла. Әлеге проект тормышка ашырыла башлаган төбәкләр юкка гына сайлап алынмаган – Татарстан һәм Мәскәү өлкәсе каты калдыклар белән электәчә генә эшли алмый, калдыклар бик күп җыела. Россиядә һәр елны 5,5 млрд тонна калдыклар барлыкка килә. Экологлар мәгълүматы буенча, шуның бары 5 процент чамасы гына эшкәртелә. Калган өлеше яндырыла, чүп-чар полигоннарына яисә законсыз чүплекләргә чыгарыла. Утильләштерү проблемасы шул кадәр өлгереп җитте ки, ул хакта хәзер илнең югары җитәкчелеге борчыла башлады. 2016 елда Дәүләт Советында Россия Президенты Владимир Путин калдыклардан котылу һәм аларны куллану проблемасын хөкүмәт эшендә мөһим юнәлешләрнең берсе дип атады.

Экологлар мәгълүматы буенча, илдә санкцияләнмәгән чүп-чар ташлау урыннары законлыларыннан 20 тапкырга артык. Стихияле рәвештә булдырылган чүп-чар ыргыту урыннары кошлар һәм вак җәнлекләр җыелу, үрчү урынына әверелеп, инфекция таралу чыганагы булып тора. Мәскәү өлкәсендә һәм Казанда Швейцария – Япония компаниясенең Hitachi Zosen заводлары төзеләчәк. Әлеге компания бөтен ил буйлап 500 завод төзегән инде: 235е – Азиядә, 250се – Европада һәм 44е – Төньяк Америкада. Германиянең Әйләнә-тирә мохитне, табигатьне, төзелеш һәм атом-төш куркынычсызлыгын саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2000 елда шушындый заводлар тарафыннан 14 млн тонна каты калдыклар эшкәртелгән. Шул рәвешле диоксиннар чыгу бары 0,5 граммны тәшкил иткән.

Карабодай, нишләп син һаман кыйммәт?

Россия Монополиягә каршы федераль хезмәтенең Татарстан идарәсенә карабодайның бәясе һаман югары булудан зарланган мөрәҗәгатьләр килеп тора.

Узган елның декабрендә әлеге уңайдан кайбер сәүдә объектларына карата эш тә ачылды. Бу юлы Монополиягә каршы федераль хезмәт алдында «Ашан», «Бәхетле – 1», «Агроторг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр, «Тандер» «ТД «Перекресток» акционер оешмалары җавап тотачак. Санап кителгән сәүдә челтәрләрен тикшергәннән соң, аларда «Көндәшлекне яклау турында»гы федераль законны бозу очраклары табылган. Монополиягә каршы органга мөрәҗәгать иткән берәү «Ашан» гипермаркетында бер атна эчендә карабодайга бәя ике тапкырга артуын әйткән. Ярманың бер килограммы 56 сумнан 97 сумга кадәр күтәрелгән. Бәя артуга башкалар да игътибар иткән. Монополиягә каршы федераль хезмәт әлеге очракны тикшерергә булган. Беренче эш 21 февральдә каралачак.

Дин әһелләре ярдәмгә килә

4 февраль ел саен Онкология авыруларына каршы бөтендөнья көрәш елы буларак билгеләп үтелә. Бу уңайдан кичә «Татар-информ» агентлыгында матбугат конференциясе узды.

Узган ел медицина өлкәсендә Онкологиягә каршы көрәш елы буларак игълан ителгән иде. Идел буе федераль округының һәм Татарстанның баш онкологы, Казан дәүләт медицина академиясе ректоры Рөстәм Хәсәнов, Республика клиник онкология диспансерының баш табибы Илдар Хәйруллин Татарстанда яман шешне кисәтү, дәвалау, авыруларны тернәкләндерү хакында сөйләде, онкологиягә кагылышлы статистика мәгълүматлары белән таныштырды.

Илдар Хәйруллин әйтүенчә, 2016 елда республикада 15545 яман шеш очрагы ачыкланган. Былтыр республикада онкология авыруларыннан үлүчеләр саны 1 процентка кимеде. Шунысы да куандыра, рактан дәваланып исәптә торучыларның 56,8 проценты биш һәм аннан да күбрәк ел яши.

Былтыр Татарстанда «Образование против новообразований» мәгълүмати кампаниясе башланган иде.

– Әлеге акциянең төп максаты – кешедә курку хисен киметү, үзеңнең сәламәтлегеңә карата кайгыртучанлыкны арттыру. Халыкта иртә диагностика узу культурасын булдырырга тиешбез. Диспансеризация үтү бик мөһим. Бу яман шеш авыруларын беренчел стадиясендә билгеләргә ярдәм итә. Ә башлангыч чорда ачыкланган яман шештән 95-99 процентта савыгырга мөмкин. Кызганыч, күпләрнең диспансеризация узарга вакытлары юк. Хастаханәдә тикшеренүләр узмыйлар. Нәтиҗәдә, 30 процент очракта рак инде соңгы стадиягә җиткән була. Бу очракта дәвалану катлаулылана. Ракны гына түгел, грипп, башка авыруларны да вакытында дәваламасаң, нәтиҗәләр аяныч булырга мөмкин бит, – ди Илдар Хәйруллин.

Әлеге мәгълүмати кампания кысаларында яман шешкә каршы шактый чаралар уздырылган. Социаль челтәрләрдә бу хакта йөзләгән язма дөнья күргән. Рак турындагы мифларга ачыклык кертү өчен төрле тестлар, биремнәр чишү мөмкинлеге дә бирелгән. Хәйрия акцияләре дә уздырылган. 13 февраль көнне, мәсәлән, онкологиядән дәваланучыларның «Без бергә» волонтер оешмасына ярдәм йөзеннән, «Ак барс» яшьләр үзәгендә «Тормыш музыкасы» дип исемләнгән концерт узачак.

Онкология авыруы диагнозы куелган өлкән кешеләр еш кына дәваланудан баш тарта. Шуңа да яман шешне кисәтү эшләрендә дин әһелләренә мөрәҗәгать итү дә нәтиҗәле булыр иде дип уйлыйлар.

Автор фотолары

Россия белән Америка дус булсын!

«Бердәм Россия» сәяси партиясенең «Яшь Гвардия» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге штабы «Политзавод» проектын гамәлгә ашыра.

– Быел республикадан 800 егет һәм кыз «Җәмәгать әйдаманы», «Сәяси технологияләр», «Яшь канунчылар» бәйгеләрендә катнашырга гариза биргән иде. Җиңүчеләр яшьләр арасында үткәреләчәк праймериз, ягъни тавыш бирү нигезендә апрель аенда ачыкланa. Йомгаклау бәйгесенең темасын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдим итте. Ул – «Дүртенче сәнәгать революциясе», – дип таныштырды «Политзавод» проекты авторы Яна Сирюкова.

Казан федераль университетының журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбендә 3 февральдә яшь активистлар: Антон Симонов, Екатерина Граф, Марсель Сираҗиев, Дарина Фролова «сәяси көрәш» мәйданчыгында сәяси фикерләү һәм оратор осталыгында көч сынаштылар. Тышкы сәясәт темасында алар: «Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин белән Америка Кушма Штатларының яңа сайланган Президенты Дональд Трамп уртак тел табарлар. Россия белән АКШ дус булырга тиеш», – дигән уртак фикерне хупладылар.

Спорт һәм допинг мәсьәләсендә фикер алышканда, яшь гвардиячеләр спортның сәяси кораллга әйләндерелүенә борчылуларын белдерделәр.

– Илләрне дуслаштыручы сыйфатында күзаллана иде бит спорт, ул шулай булырга тиеш тә, – диде Марсель Сираҗиев.

– Россия паралимпиячеләрен уеннарда катнаштырмау, гомумән, акылга сыймаслык гамәл, – диде Дарина Фролова.

Казан федераль университетының яшь укытучысы Марсель Сираҗиев мәгариф темасына «фикер бәйгесендә» электрон укыту алымы ул өстәмә чара гына булырга тиеш, укытучының балалар белән турыдан-туры аралашуы мөһим дип белдерде һәм аудиториядәге яшь гвардиячеләр тарафыннан көчле теләктәшлек тапты. Россия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советында Татарстан вәкиле Олег Морозов рәислегендәге жюри да Марсель Сираҗиевны бәйгенең чираттагы этабы җиңүчесе, дип белдерде. Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенең күчмә Кубогы Марсельгә тапшырылды.

– Тәҗрибә туплауда, сәясәт беләнмә ирешүдә «Политзавод» бик кирәкле башлангыч. Бәлки, шушыннан киләчәктә Татарстанның, хәтта Россиянең сәясәт йолдызлары, танылган сәясәтчеләре чыгар, – диде Олег Морозов.

«Бердәм Россия» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге башкарма комитеты җитәкчесе Андрей Кондратьев яшьләрне җәмәгать тормышында актив катнашырга чакырды. «Үзеңне танытуда «Политзавод» – менә дигән мәйданчык», – диде ул.

«Бердәм Россия» сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлегенең, «Яшь Гвардия»нең төбәк штабының рәсми сайтларындагы яшьләргә кагылышлы программа-чаралар белән даими танышып бару, әлеге чараларда катнашу зарур. Бу – үзеңне таныту мөмкинлеге.

Дамир БӘДРИЕВ.

Җиде ел бушка узарга тиеш түгел

1-2 февраль көннәрендә Татарстан башкаласына, тәҗрибә уртаклашу максатыннан, Россия хәрби уку йортлары вәкилләре җыелды. Биредә алар «Коры җир гаскәрләре урта һөнәри белем бирү оешмаларында мәгариф. Белем бирү сыйфатын үстерү» дигән темага түгәрәк өстәл үткәрде. Хәрбиләр әзерләүче югары уку йортлары иң беренче чиратта суворовчылар һәм кадет мәктәпләреннән сыйфатлы кадрлар көтә.

Алисә САБИРОВА

Түгәрәк өстәлдә четерекле мәсьәләләр күтәрелде. Коры җир гаскәрләре гаскәри башлыгы генерал-полковник Олег Салюков, бүген суворовчыларга ватанпәрвәрлек, үз уку йорты өчен горурлык хисе җитеп бетми, ди.

– Күптән түгел генә 20 ел элек Суворов көллиятен тәмамлаган кеше белән очраштым. Аның нәкъ менә шушы уку йортында белем алуы турында горурланып сөйләвен күрсәгез иде. Безнең укучылар да шундый булсын иде, ләкин әлегә нәкъ киресе килеп чыга. Ата-аналар безгә балаларын төрле тәрбия алсыннар, йомшак булып үсмәсеннәр дип бирә. Безнең максат ул гына түгел. Без булачак хәрбиләрне әзерләргә тиеш. Әлегә гомуми белем бирү буенча да артта барабыз. Мәсәлән, Мәскәүдәге суворовчылар көллиятендә математика буенча белем бирү иң түбән дәрәҗәдә. Казан гына яхшы күрсәткечләр бирә. Укытучылар, без тәрбиячеләр түгел, дип чаң суга. Хәрби уку йортында андый хәл булырга тиеш түгел. Укытучы җаны-тәне белән биредә булырга тиеш. Балаларның 30-40 проценты, безнең уку йортын тәмамлагач, хәрби юлдан баш тарта. Димәк, шушы җиде ел эчендә без анда хәрби кеше әзерли алмадык, бу эшкә мәхәббәт тәрбияләмәдек. Бу безнең хата, – дип кызып-кызып сөйләде Олег Салюков.

Ул, суворовчылар өчен «Юнармия хәрәкәте»нә кушылу да файдага булачак, дип белдерде.

– Пионерлар заманы үтте, ә алардан соң килгән бушлыкны ни беләндер тулыландырырга кирәк. Урам тәрбиясе алганчы, «Юнармия хәркәте»нә кушылу кирәк. Бирегә 8-18 яшьлек егетләр керә ала. Җәй көне хәрби-патриотик лагерьлар оештыралар, спорт секцияләре бар. Олимпия чемпионнары да юнармеецлар белән даими очрашып тора, – диде Олег Салюков.

Гади мәктәптән килгән укучы да, Суворов, кадет мәктәпләрен тәмамлаганнар да югары хәрби уку йортларына бертигез дәрәҗәдә Бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре белән керә. Ләкин хәрби мәктәпне узганнарга тәртип, билгеләр нәтиҗәсенә карап, тагын өстәмә балл бирәләр.

– Ул бит җиде елын безнең кул астында укыды. Бу вакыт бушка үтәргә тиеш түгел. Безнең көллиятне тәмамлаучыларның, хәрби уку йортларына кергәндә, төп имтихан күрсәткечләренә 10 балл өстәлергә тиеш. Югары уку йортлары белән тагын да тыгыз элемтә булдырырга кирәк. Уку йортлары безгә килеп балаларның белем дәрәҗәсен тикшерсә, кайсы якка басым ясарга кирәклеген әйтсә, тагын да яхшырак булыр иде, – диде генерал-полковник.

«Сәләт» җәйгә әзерләнә

Бу көннәрдә «Балтик» лагеренда «Сәләт»нең «Әйдаманнар мәктәбе» эшли. Анда Татарстан, Башкортстан, Чувашия, Мордовия, Дагыстан республикалары, Киров, Саратов һәм Самара өлкәләреннән җыелган 130 әйдаман, 27 куратор катнаша.

«Әйдаманнар мәктәбе» – «Сәләт»нең җәйге профильле сменалары өчен җитәкчеләр һәм әйдаманнардан торган бердәм команда туплау максатыннан оештырылган проекты. Анда төрле юнәлешләрдә дәресләр алып барыла.

Лагерьга «Сәләт» фондының Попечительләр советы рәисе, Россия Дәүләт Думасы депутаты Марат Бариев та килеп китте. Ул «Әйдаманнар мәктәбе»ндә укучыларга балаларга файдалы да, күңелле дә җәй бүләк итүләрен теләп калды.

Элина Степанова, проект җитәкчесе:

– Биредә иң әйбәт әйдаман булырга теләүчеләр җыелган. Алар быелгы җәйләрен үз белемнәрен, осталыкларын безнең сәләтле балаларыбыз белән эшләү өчен файдаланачак. Командабыз бик дус, көчле армиягә тиң. Бергә булганда, берникнди киртәләр дә куркыныч түгел.

Минемчә, беренче чиратта, әйдаман җаваплы кеше булырга, конкрет биремнәрне чишә белергә тиеш. Балалар күңелен аңлый белү, аларны хөрмәт итү дә бик мөһим, чөнки һәр бала – шәхес.

Альбина Кадыйрова, проектның кураторы:

– Катнашучыларыбыз шәп! Без аларга зур өметләр баглыйбыз. Һәммәсенең күзләре янып тора, балалар белән эшләргә теләкләре зур. Әйдаман – балалар өчен үрнәк ул, алар аңа охшарга тырыша. Шуңа да ул һәр сүзен чамалап сөйләргә, эшен уйлап башкарырга тиеш. Әйдаман – әйбәт психолог, шәп модератор, креатив менеджер да. Тулаем алганда, катнашучылар нәкъ шундый. Энергияләре ташып тора, бик шаяннар.

Булат Вәлиуллин, мәктәпнең кураторы:

– «Сәләт»тә мин 2011 елдан бирле. «Шәхес», «Раушан», «Санак»та булдым, «Сәләт-Самара» кышкы сменасында катнашырга өлгердем. «Сәләт-Бөгелмә» клубының кураторы да мин.

Вакыт бушка узмый, һәр булачак әйдаман алыштыргысыз тәҗрибә туплый. Без аларның эшчәнлеген күзәтәбез, командаларыбызга иң көчле әйдаманнарны тупларга тырышабыз.

Айнур Шәйдуллин, Чувашия, катнашучы:

– Әйдаман – сәлкешләр өчен үрнәк һәм лидер. Безнең команда бик көчле. «Әйдаманнар мәктәбе»ндә күп белем тупладым, үземне яңа яктан ачтым.

Эльмира Сермукова, Саратов өлкәсе, катнашучы:

– Бик-бик җаваплы әйдаман булачакмын, һәр бала белән иҗади эшләячәкмен. Һәммәсен яратачакмын. Җәйне көтәм, үзем барачак сменаны иң әйбәте итәр өчен бар көчемне куярга әзермен!

Рәмиз Муллагамедов, Дагыстан, катнашучы:

– Әйдаман ул гадәти кеше түгел. Ул барысын да булдырырга, күп белергә тиеш. Балаларны тынычландыру, кәефләрен күтәрү, аңлау җиңел эш түгел. Магистратурага укырга керү өчен зур педагогик тәҗрибә туплый алдым. Моның өчен «Сәләт»кә зур рәхмәт! Ул бу эштә ышанычлы чыганак. Минем өчен монысы бик мөһим. Татар теле белән әлегә авыррак, тик тырышачакмын. Без бит бер гаилә!

Хәсән Туфан сөенер иде

Камал театрының кече сәхнәсендә «Агыла да болыт агыла» диген шигъри спектакль күрсәтелде. Ул күренекле әдипләр Хәсән Туфан һәм Туфан Миңнуллин әсәрләренә нигезләнеп эшләнгән. Яшь режиссер Айдар Җаббаров мондый формадагы спектакльне сәхнәләштереп күрсәткән иде инде. Бу юлы да аның таланты сөендерде.

Спектакль Хәсән Туфанны үлем җәзасына хөкем итүдән башланып китте. Әмма гомере бетмәгән, күрәсең, аны Себергә сөргенгә озаталар. Поездда барганда латыш, украин, рус егетләре белән таныша. Кызы Гөлгенә белән улы Идегәйне сагынып, алар өчен борчылып хатыны Луизага язган хатлары үзәкләрне өзәрлек. Үзен Себердә ялгыз рус хатынына димләсәләр дә, ризалашмый Хәсән. Ялгыз гомер кичерә, Луизасы белән күрешүгә өметен җуймый. Туфанның кичерешләре шигырь юллары аша бәян ителә. Яшь Хәсәнне – Раил Шәмсуаров, ә өлкәнен Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов уйный. Спектакльдә шулай ук Алмаз Сабирҗанов, Илнур Закиров, Йосыф Бикчәнтәев, Фәннүр Мөхәммәтҗановлар катнашты. Һәркайсының уйнавын тамашачы яратып кабул итте.

Әлеге спектакльне караганда, шагыйрьнең аянычлы язмышын күздән кичерде тамашачы. Чын шигърият белән кабат очрашты.

Заманында студент чакларда университет аудиториясендә Хәсән Туфанга багышланган кичәдә, аның алдында шигырьләрен укыган вакытларны искә төшердем. Әгәр исән булса, мондый спектакль эшләүләренә Хәсән Туфан үзе дә сөенеп утырыр иде.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

Әлмәттә театрны урамда да караячаклар

Узган ел Нефтьчеләр көнендә Әлмәттә чакырылган урам театрлары чыгышлары белән «Җете кешеләр» фестивале оештырылган булса, быел инде әлмәтлеләр үзләре Урам театры идеясен тормышка ашырмакчылар. Бу юнәлештә эш инде башланган.

– Урам театры – халыкны җәлеп итү өчен искиткеч кызыклы сәнгать. Без шул теманы өйрәнәбез. Аны «Татнефть» белән бергәләп гамәлгә кую программасы эшләнә, – дип белдерген «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына Әлмәт татар дәүләт театры директоры Фәридә Исмәгыйлева.

Урам театры оештыру «Татнефть»нең генераль директоры Наил Магановның идеясе икән. Соңгы өч айда гына да бу мәсьәлә үңаеннан ике тапкыр сөйләшү узган.

ФГБОУ ВО «КАЗАНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АГРАРНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОБЪЯВЛЯЕТ КОНКУРС НА ЗАМЕЩЕНИЕ ВАКАНТНЫХ ДОЛЖНОСТЕЙ ПРОФЕССОРСКО-ПРЕПОДАВАТЕЛЬСКОГО СОСТАВА

1. Доцентов кафедр:
- машин и оборудований в агробизнесе – 1
- растениеводство и плодоовощеводство – 1

Ученый совет Института Механизации и Технического сервиса состоится 9 марта 2017 года.

Ученый совет агрономического факультета состоится 16 марта 2017 года.

Срок подачи заявлений – один месяц со дня опубликования в газете.

АДРЕС: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 65.

tatar-inform.ru

Аяк булмаса, куллар бар

Шагыйрь Фәнис Яруллин: «Дөп-дөп атлап киткән кешеләргә сокланып карап калам», – дип язган иде, хәтерләсәгез. Гомере буена урын өстендә ятарга мәҗбүр булган ир-атның җан әрнүле сүзләре бу.

Сәламәт чакта аз гына сырхауласак та, дөньяның бер мескененә әйләнәбез дә бетәбез. Үзебезне физик мөмкинлекләре чикле, ягъни чын мәгънәсендә гарипләр белән чагыштырып карамыйбыз.

«Локомотив» базасында узган атнада «Казан марафоны» халыкара чаңгы ярышлары узды. Анда Россия, Казахстан, Чехия спортчылары катнашты. Спортчылар сафында Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов, Татарстан Республикасының чаңгы һәм биатлон узышлары буенча федерациясе президенты Илшат Фәрдиев, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов, чаңгы узышлары буенча дүрт мәртәбә Олимпия чемпионы Николай Зимятов та бар иде.

– Биш чакрым арага чаңгы һәм биатлон узышлары буенча Россия паралимпия җыелма командасы да чыкты. Алардагы көчле рух сокланырлык, – ди шәһәр Башкарма комитетының физкультура һәм спорт комитеты рәисе Светлана Вострикова.

Биш километр араны чаңгыда беренче булып Айдар Сәгыйтдинов, Татьяна Свередова, ә яшьләрдән Алексей Бульбов килде. 25 километрда ир-атлардан Алексей Овчинников, хатын-кызлардан Екатерина Варакина җиңде. 50 километрлы дистанциядә Ольга Рочева белән Михаил Девятьяров финишка беренче булып килде.

– Казанлыларның 40,1 проценты спорт белән даими шөгыльләнә. ГТО нормативларын 12 меңнән артык кеше тапшырды. Бу сан буенча да без Россиядә – беренче. Мәскәүнең үзендә дә ГТО нормативларын тапшыручылар нибары 10 меңнән артык. Казанда спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр зур, – дип чыгыш ясады Светлана Вострикова «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Казанда хәзер спорт корылмалары саны – 2027. Узган ел гына да 61 спорт корылмасы файдалануга тапшырылды. Шулар арасында иң зурлары: Оренбург трактындагы бадминтон үзәге, «Олимпиец» спорт комплексында 50 метрлы бассейн, Горки-Әмәт урманында чаңгы трассасы.

– «Казан» ат-спорт комплексында хәйриячеләр ярдәмендә өсте ябулы манеж төзелде. Анда инвалид балалар өчен быелның 1 февраленнән ипотерапия программасы буенча бушлай күнегүләр башланды, – дип хәбәр итте Светлана Вострикова.

Дәрвишләр бистәсендәге «Ракета» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе территориясендә йөзү бассейны, ә Горький шоссесындагы 3нче гимназия янында чаңгы базасы төзү планлаштырылган. Бюджеттан тыш чыганакларга «Тасма» стадионында футбол уеннары өчен өсте ябулы манеж сафка бастыру күздә тотыла.

Дамир БӘДРИЕВ.

6-13 февраль көннәрендә Яшел Үзәннең «Маяк» спорт комплексында авыр атлетика буенча Россия Кубогы ярышлары уза. Бу турнир быел илнең иң көчле атлетлары өчен беренче зур чара. Биредә Россиянең 40 төбәгеннән 300гә якын спортчы катнашыр дип көтелә.

Авыр үлчәүдә

Зөлфәт Гәраев.

Татарстан данын 11 спортчы яклаячак (җиде ир-ат, дүрт хатын-кыз). Исемлектә яшүсмерләр арасында Европа беренчелеге җиңүчесе Надежда Лихачева, яшүсмерләр арасында үткән дөнья беренчелеге бронза призеры Зөлфәт Гәраев тә бар.

– Минем әти – физкультура укытучысы. Алты яшьтән ул мине йөгерү буенча төрле ярышларга әзерләде. Соңыннан абый авыр атлетика белән шөгыльләнә башлады. Миңа да спортның бу төре ошады, үзем дә шөгыльләнә башладым. Спортка беренче адымнарны ясаганда җәрәхәтләр турында уйламыйсың. Аллага шөкер, әлегә җитди травмалар алган булмады, – дип сөйләде безгә үзенең спортка ничек килүе турында Зөлфәт Гәраев.

Быел ул үзен беренче тапкыр ирләр категориясендә сынаячак. Максаты – ярышларда яхшы нәтиҗәгә ирешеп, халыкара класслы спортчы исемен алу. Ә инде 2024 елда ул Олимпия уеннарында катнашырга җыена.

Турнирның мәртәбәле кунаклары арасында Россиянең авыр атлетика буенча Федерация президенты Владимир Салтыков, илнең авыр атлетика буенча ир-атлар һәм хатын-кызлар Россия җыелмасы тренеры, олимпия чемпионы Николай Колесников һәм Павел Кузнецов та катнашачак. Шулай ук ярышлар барышында авыр атлетикага багышланган конференция була.

Николай Колесников ярышларда хатын-кызлар өчен күбрәк борчылганын, алар белән озак вакыт уртак тел таба алмавын искә төшерде.

– Мин бит башта ирләр белән эшләдем. Хатын-кызлар командасына килгәч, югалып калдым. Аларның бит холкы бүтән. Ирләр белән ирләрчә сөйләшеп була. Ә хатын-кызлар арасында берсенә күбрәк игътибар бирсәң, үпкәләш китә. Хәзер җаен таптык инде: ирләр дә, хатын-кызлар да бергә шөгыльләнә. Командага бу тагын да көчле мотивация бирә, – ди ул.

Россия төбәкләреннән тыш, ярышларга Казахстан белән Үзбәкстан спортчылары да киләчәк.

ТӘРТИП кирәк безгә

«Тәртип FM» радиосы контенты «Болгар радиосы»на биреләчәк, дип яза «Татар-информ». Исегездә булса, татар телендә сөйләүче «Тәртип FM» радиосы быелның 1 февралендә эшләүдән туктады, ул билгән ешлык (Казанда FM-диапазонда 93.5 МГц) «РуМедиа» холдингына сатылу сәбәпле, анда хәзер Мәскәүнең Business FM радиостанциясе сөйли.

«Тәртип FM»ны саклап калу максатыннан, радионың элеккеге баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлова интернетта Россия Президенты Владимир Путинга петиция язган иде. Петициягә имзалар җыю әле дә дәвам итә.

Әлеге мәсьәлә узган атнада «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы утырышында да кузгатылды. Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте директорлар советы рәисе Әсгать Сафаров:

– Татар халкы аны яратып тыңлый, шуңа күрә без вариантларны, бу мәсьәләнең чишелешен табарбыз, – дигән иде.

«Адымнар» тапшыруыннан билгеле булганча, «Тәртип FM» радиосы контенты «Болгар радиосы»на биреләчәк.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 5719.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 673. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы